**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 6 июнендәге 2328 номерлы карары

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 3434 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары балаларына күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының балаларына социаль ярдәм күрсәтү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 3434 номерлы карарына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 13 мартындагы 740 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 1423 номерлы, 2023 елның 15 ноябрендәге 3511 номерлы, 2023 елның 4 декабрендәге 3833 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Казан шәһәре территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган һәм махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары балаларына, махсус хәрби операциядә катнашып һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнары балаларына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнүче, ирнең (хатынның) беренче (башка) никахыннан туган балаларына, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар һәм хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларын ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре балаларына, Казан шәһәренең шәһәр пассажир транспортында исемле электрон юл билетлары (транспорт картасы) (алга таба – электрон юл билеты) буенча 2022 елның 10 октябреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр бушлай йөрү мөмкинлеге биреп, социаль ярдәм чараларын билгеләргә»;

1.2. 2 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Электрон юл йөрү билеты махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының 8 яшьтән алып 18 яшькә кадәр балаларына, махсус хәрби операциядә катнашып һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнарының балаларына, белем бирү эшчәнлеген

башкаручы оешмаларда урта һөнәри һәм югары белем бирү программалары буенча көндезге формада белем алучы балаларына уку тәмамланганчы, әмма 23 яшькә кадәр, Казан шәһәренең барлык төр шәһәр пассажир транспортында йөрү хокукын бирә.

Электрон юл йөрү билеты яшәү урыны буенча Казан шәһәре территориясендә теркәлгәннәргә бирелә. Казан шәһәре территориясендә теркәлмәгән очракта, электрон юл йөрү билеты Казан шәһәре гомуми белем бирү учреждениесендә уку турында белешмә нигезендә бирелә»;

1.3. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1. түбәндәге документлар нигезендә:

- махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының балаларына – махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары белән туганлыкны раслаучы документлар;

- махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнүче ирнең (хатынның) беренче (башка) никахыннан туган балаларына – язылышу турында таныклык;

- махсус хәрби операциядә катнашып һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнарының белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмаларда урта һөнәри һәм югары белем бирү программалары буенча көндезге формада белем алучы балаларына (әлеге укуны тәмамлаганчы, әмма 23 яшькә кадәр) – хәрби хезмәткәрнең махсус хәрби операция барышында бурычлар башкарганда һәлак булуын раслый торган документ»;

1.4. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

4.1. махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары балалары һәм махсус хәрби операциядә катнашып һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнары балалары өчен электрон юл йөрү билетларын әзерләргә;

4.2. махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының балаларына һәм махсус хәрби операциядә катнашып һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнарының балаларына Казан шәһәренең барлык төр шәһәр пассажир транспортында электрон юл йөрү билетлары буенча бушлай йөрү мөмкинлеген бирергә»;

1.5. карарның кушымтасы гамәлдән чыккан дип танырга;

1.6. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 3434 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр

басмасында (www.docskzn.ru) рәсми рәвештә басылып чыккач гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 6 июнендәге
2328 номерлы карарына кушымта

(форма)

Казан шәһәренең
____________________________________ районындагы
__________________ номерлы мәктәп/гимназия/лицей
(кирәклесенең астына сызарга)
________________________________________________
(башка белем бирү учреждениесе)
җитәкчесенә______________________________________
____________________________ адресы буенча яшәүче
____________________________________________
___________________________________________
(атасының яки анасының (законлы вәкиленең)/18 яше тулган баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)

гариза.

Сездән
___________________________________________________________________________________
(махсус хәрби операциядә катнашучы яки һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданинының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
____________________________________________________________________________ булып торган
_________________________________________________________________________________
(улы/кызы/опекага алынган зат)
_________________________________________________________________________________
(махсус хәрби операциядә катнашучы яки һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданины баласының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
электрон юл билеты бирүегезне сорыйм.
Кушымта:
___________________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________________
____________________________________________.
(туу турында таныклык/махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданины белән туганлыкны таныклый торган башка документ, язылышу турында таныклык күчермәсе; хәрби хезмәткәрнең махсус хәрби операция барышында һәлак булуын раслаучы документ)

_________________ (имза) ____________________________________ (имзаның аңлатмасы)

202___елның «_____» ______________